Хезмәт торагына торак йортлар, торак йортлардагы аерым фатирлар кертелә ала

1.6. Татарстан Республикасының махсус торак фонды составыннан йортлар, йортларның өлешләре, фатирлар һәм бүлмәләр чыгарыла ала.

1.7. Тулай тораклардагы бүлмәләрне Татарстан Республикасының махсус торак фонды составыннан чыгару түбәндәге шартлар үтәлгәндә гамәлгә ашырыла ала:

а) торакның 2006 елның 28 гыйнварендәге № 47 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Торак биналар» дәүләт төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре (СНиП 2.08.01-89) белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

б) һәр фатирга баскыч торыгыннан яисә коридордан аерым керү урыны булу;

в) бүлмәләрнең һәм инженерлык җиһазларының канәгатьләнерлек техник, янгынга каршы, санитар-гигиена торышы;

г) гаиләләрне бүлмәләп (фатирлап) урнаштыру; тоташтырылган һәм үтеп йөрешле бүлмәләргә бер гаиләне урнаштыру; койко-урын шартларында урнаштырылган бүлмәләрнең булмавы;

д) тулай торакларда торак мәйданы бирелмичә теркәлгән һәм (яисә) озак вакыт (алты ай буе) теркәлгән урынында яшәмәүче гражданнарның булмавы;

е) тулай тораклар планировкасындагы рөхсәтсез үзгәртүләрне кире үз хәленә кайтару;

ж) торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар булмау.

1.8. Хезмәт торакларын Татарстан Республикасының махсус торак фонды составыннан чыгару аларда түбәндәгеләр яшәгәндә гамәлгә ашырыла ала:

- үзләренә хезмәт торагы биргән предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, оешмаларда ун елдан күбрәк эшләгән гражданнар яисә гражданнарның бюджет тармагында гомуми эш чоры ун елдан да ким булмау шарты белән;

- хезмәт вазыйфаларын яисә хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган (вафат булган) яисә хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрләр, вазыйфаи затлар, эчке эшләр органнары, иминлек федераль хезмәте органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәт органнары, наркотик чаралар һәм психотропик матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнары, җинаять-төзәтү системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең гаилә әгъзалары;

- хезмәт торагы бирелгән һәм вафат булган хезмәткәрләре хезмәткәрнең гаилә әгъзаларына;

- картлык буенча пенсионерларга;

- эш бирүче гаебе белән инвалидлык алган I яисә II төркем инвалидлары, хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә профессиональ чир алган I яисә II төркем инвалидлары, хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә яраланган, контузия яисә җәрәхәт алган яисә хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле чир алып I яисә II төркем инвалидлары.

Министрлык карарына яисә баш тарту турында Министрлык карарына кул куя һәм рәсмиләштерү өчен эш башкару бүлегенә юллый

Кул куелган Министрлык карары яисә баш тарту турында Министрлык карары

Эш башкару бүлеге белгече

Министрлык карарын яисә Министрлыкның баш тарту турында карарын рәсмиләштерә.

Гариза бирүчегә җибәрелгән Министрлык карары яисә баш тарту турында Министрлык карары

